БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28 апрель 2018 ел № 121

## 2017 елга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексына, Татарстан Республикасы Бюджет кодексына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында бюджет процессы турында нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар бирде:**

1. 2017 елга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында хисапны керем буенча 927025,85 сум күләмендә, чыгым буенча 903116,57 сум күләмендә, керемнәрнең чыгымнардан 23909,28 мең сумга артуы белән (Балтач муниципаль районы бюджеты профициты) һәм түбәндәге күрсәткечләр белән расларга:

керем төрләре кодлары, керемнәр төрчәләре, керемнәр төрләре, бюджет керемнәренә керә торган дәүләт идарәсе секторы операцияләре классификацияләре кодлары буенча Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәрен әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә;

бюджетлар керемнәре классификациясе кодлары буенча Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәрен әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә;

Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы буенча Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты чыгымнарын әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә;

бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты чыгымнарын әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә;

максатчан статьялар (дәүләт һәм муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программадан тыш юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре, бүлекчәләре буенча Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты чыгымнарын әлеге карарга 7 нче кушымтасы нигезендә;

төркемнәр, төркемчәләр, статьялар кодлары буенча Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын, бюджет дефицитын финанслау чыганакларына керә торган дәүләт идарәсе секторы операцияләре классификациясенең бюджет кытлыгын финанслау чыганакларын төрләре әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә;

бюджетлар кытлыгын финанслау чыганаклары классификациясе кодлары буенча Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарны baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин